**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«18» май 2022 ел Иштирәк авылы №20/3

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 18 февралендәге 43/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 19 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 18 февралендәге 43/1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 31 статьяның 31.11 пункты 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр»;

1.2. 20 статьяның 20.1 пункты 2 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Г.С. Гарифуллина